РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

13 февраль 2015ел № 8-45

**«Буа район Советының 2005 елның 30 декабрендәге 24-4 номерлы карары белән расланган Буа район башкарма комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Буа муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Буа район Советының 2005 елның 30 декабрендәге 24-4 номерлы карары белән расланган Буа район башкарма комитеты турындагы нигезләмәгә (04.04.2011 №5-8, 16.03.2012 №6-17 карарлары редакциясендә) ( алга таба текст буенча- Нигезләмә–), киләсе үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең 4.7. бүлегендәге з) пунктында текстны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

з) мәгариф өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча башкарма комитет вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

- муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш);

- муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру (балаларны өстәмә укытудан тыш, аларны финанс ягыннан тәэмин итүне Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары гамәлгә ашыра торган балаларга өстәмә белем бирүдән тыш);

- муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләүне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

- муниципаль мәгариф оешмаларын булдыру, үзгәртеп оештыру, бетерү (муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан югары белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларын төзүдән тыш), муниципаль мәгариф оешмаларын гамәлгә куючыларның функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру;

- муниципаль мәгариф оешмалары биналарын һәм корылмаларын тотуны тәэмин итү, аларга якын территорияләрне төзекләндерү;

- мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча мәҗбүри укытылырга тиешле балаларны исәпкә алу, муниципаль мәгариф оешмаларын Буа муниципаль районының конкрет территорияләренә беркетү;

- Буа муниципаль районы территориясендә урнашкан муниципаль мәгариф оешмалары филиалларын төзү, Буа район башкарма комитеты белән килештереп, гамәлгә ашырыла;

- гамәлгә куючысы булган мәгариф оешмасы җитәкчесен билгеләү;

- гамәлгә куючысы муниципаль белем бирү оешмасы җитәкчесе вазыйфасына кандидатларга аттестация үткәрү тәртибен һәм срокларын билгеләү;

- һәр дәрәҗәдәге һәм тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә яшәүче балаларның гомуми белем алу хокукына ия һәм ата-аналар (законлы вәкилләр) тарафыннан

билгеләнгән белем алу рәвешләрен исәпкә ала. Балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) гаилә берәмлеге формасында гомуми белем алу рәвешен сайлаганда, ата-аналар (законлы вәкилләр) үзләре яши торган территорияләрдә муниципаль районның җирле үзидарә органын сайлау турында хәбәр итә;

- балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) гаризасы буенча, әгәр әлеге белем бирү оешмасын гамәлгә куючы булса, башлангыч гомуми белем бирүнең уку-укыту программалары буенча белем бирү оешмасына балаларны кабул итүне иртәрәк яисә соңгырак яшьтә рөхсәт итәргә хокуклы. Мәгариф оешмаларында мәктәпкәчә белем алу балалар ике айга җиткәннән башлана ала. Мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем алу сәламәтлеге торышы буенча каршылыклар булмаса да, балаларга алты яшь һәм алты ай тулгач, әмма алар сигез яшькә җиткәннән дә соңга калмыйча башлана;

- ата-анадан (законлы вәкилләрдән) алына торган баланы карап торган һәм караган өчен түләү һәм, әгәр шушы белем бирү оешмасын гамәлгә куючы булса, аның күләме билгеләү хокукына ия. Гамәлгә куючы ата-ана түләвенең күләмен киметергә яисә ул билгеләгән очракларда һәм тәртиптә ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) аерым категорияләреннән аны түләтмәскә хокуклы;

- ата-аналар (законлы вәкилләр) гаризасы буенча балаларны башлангыч гомуми белем бирүнең уку-укыту программалары буенча белем бирү оешмасына иртә яисә аннан да соңга калмыйча алуны рөхсәт итәргә хокуклы;

- мәгариф системасы турында мәгълүматның ачыклыгын һәм һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итү максатында мәгариф системасы мониторингын башкара

- мәгариф өлкәсендә Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Әлеге карар якын араларда басылып чыккан басма массакүләм мәгълүмат чараларында хокукый акт тексты басылып чыккан вакыттан, шулай ук текстны Буа муниципаль районы Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә районның рәсми сайтында урнаштырылган вакыттан алып законлы көченә керә http://Buinsk.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль милеккә һәм җирле үзидарәгә идарә итү мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Буа муниципаль районы Советы рәисе А.К.Айзетуллов